…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№1 2013. 2 октябрь
**УКЫТУЧЫЛАР БӘЙРӘМЕНӘ БАГЫШЛАНГАН МАХСУС ЧЫГАРЫЛЫШ**

***5 нче октябрь – Халыкара укытучылар көне.***



***Хөрмәтле коллегалар!***

***Сезне профессиональ бәйрәмебез белән ихластан котлыйм. Йөрәк җылыгызны биреп, күңелегездәге бар яхшылыкны балаларга бүләк итеп башкарган хезмәтегез өчен зур рәхмәтемне белдерәм. Һәрвакытта гаиләгездәгеләрнең теләктәшлеген тоеп, исән-имин эшләвегезне телим. Бер-беребезне аңлап, укучыларыбызның хөрмәтен, яратуын тоеп озак еллар бергә-бергә хезмәт итәргә насыйп булсын.***

Мәктәп директоры Нуртдинов Наил Рөстәм улы.

Һәрбер кеше дә диярлек гомеренең унбер елын мәктәптә үткәрә. Анда ул укый, яза, белем ала. Тупланган белемнәре белән уку йортына керә. Аны тәмамлап эшкә урнаша, тормышта үз юлын таба. Һәм боларның барысы белән дә үзенә юл күрсәтүче – укытучыга бурычлы. Бер яктан укытучы бер гади профессия кебек: укучылардан үткән теманы сорыйсың, "5" яки "2" куясың, дәрес аңлатасың, һәм шуның белән бетте. Ләкин бу эшкә тирәнрәк карасаң, аның бик күп авыр якларын күрергә була. Беренче укытучыбыз безне кулга каләм тотып язарга, хәрефләр җыеп укырга, санарга өйрәтә. Башлангыч сыйныфларны тәмамлагач һәр предметтан аерым укытучы укыта башлый, монда аларның зур профессиональлеге таләп ителә. Һәрбер укытучы журналга билге куяр өчен түгел, ә укучылар ни дә булса аңлап калсын өчен тырыша. Мәктәптән кайткач та ул дәфтәрләр тикшерә, киткән хаталар өчен борчыла, икенче көнгә дәрескә әзерләнә, һәм һәр укучыга һәрвакыт бары яхшы теләкләрдә генә кала.

Сүземне тәмамлап барлык укучылар исеменнән шуны әйтәсем килә: без яраткан сыйныф җитәкчеләребезне, мәктәбебездә озак еллар укучыларга белем бирүче һәм яңа гына килгән укытучыларны – барыгызны да бу һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез, сезгә нык исәнлек, гаилә бәхете, олы сабырлык, зур уңышлар телибез. Сезнең хезмәтегез бәяләп бетергесез. Бәйрәмегез белән хөрмәтле укытучыларыбыз!

Газимзянова Рания (9 нчы Б сыйныфы укучысы)

# ...безгә язалар...

Укытучы…   Шушы сүзне ишетүгә без үзебезне укыткан укытучыларыбызны күз алдына китерәбез. Шулар арасында математика укытучыбыз Резеда апа үзенең һәрвакыт шат йөзле, мөлаемлеге белән аерылып тора. Аның һәр дәресе мавыктыргыч һәм кызыклы үтә. Ул еш кына шаян сүзләр белән безнең дә кәефебезне күтәрә. Резеда апа дзресне бик яхшы аңлата, шуңа күрә аның дәресләрен көтеп алабыз, гел яхшы билгеләр генә алабыз. Ул бар күңелен биреп, дәрес аңлата, өстәмә шөгыльләнә. Без апабызны чын күңелдән хөрмәт итәбез, аның тырышлыгы безнең өчен бик кадерле.Резеда апа безгә һәрвакыт үрнәк булып калачак, чөнки ул безне бары тик яхшыга гына өйрәтә, киләчәктә дөрес итеп үз юлыбызны таба алуыбызны тели. Без аны һөнәри бәйрәме белән тәбрик итәбез һәм озын гомер, исәнлек, тормыш юлының шатлык һәм бәхетләргә генә үрелеп баруын телибез.

*9 нчы А сыйныфы укучылары исеменнән Ләйлә Шәйхетдинова.*

...Бишенче сыйныфта җитәкчегез Мубаракшин Илдар абыегыз була дигәч, күңелләребезгәниндидер бер курку кергән иде. Ләкин ул тиз арада юкка да чыкты. Үзенең сабырлыгы, тапкыр теле, һәр мәсьәләгә тиз арада чишелеш таба алуы белән ул күңелләргә үтеп керде. Илдар абый безнең киләчәк өчен кайгыра, киңәшләре белән ярдәм итә, чын ир-атның шәхси үрнәгендә тәрбия бирә.

Безгә авыр булса, аңа да бик авыр. Укытучыбыз! Гел шундый әйбәт булып калыгыз, безне 11 нче сыйныфка кадәр озатып барыгыз! Без сезне бик яратабыз, сезнең белән горурланабыз!

*9 нчы А сыйныфы егетләре исеменнән*
*Раил Шәрифуллин*

Укытучы – иң авыр һөнәрләрнең берсе ул, минемчә. Укытучы булу зур сабырлык, түземлек һәм тырышлык таләп итә. Балалар белән уртак тел табып, аларга белем бирү бик җиңеллләрдән түгел шул. Иң яраткан укытучыларыбыздан берсе – Флера Миндаровна турында язасыбыз килә. Флера апа бик тырыш, үз эшенә җаваплы караучы укытучы. Ул безнең белемебез өчен бик күп көч куя. Нинди генә авыр темалар булмасын, ул безгә аны җиңел итеп аңлата. Ә үткән ел без аның белән бергәләшеп ГИАга әзерләндек. Һәр биремнең төбенә төшеп, һәр кайсыбыз белән индивидуаль шөгыльләнде ул. Шуңа да барыбыз да имтиханнарны уңышлы тапшырдык. Ә хәзер инде БДИга әзерлек алып барабыз. Флера апа! Сезне бәйрәм белән тәбрик итеп, сезгә бәхет, уңышлар, сәламәтлек телибез.

*10 нчы сыйныф укучылары исеменнән*
*Галимова Алсинә һәм Вәлиева Миләүшә*

Укытучы һөнәре бик җаваплы һәм авыр эш. Балаларны тәбияләү, аларга белем бирү, бер нәсә дә аңламаган балаларны укытып тормыш юлына бастыру өчен бик күп көч кирәк. Безне барысына да өйрәтүче класс җитәкчебез Абунагимова Галия Сәлихҗан кызы. Галия апа безне күптәннән бирле укыта. Нинди генә ярдәм белән , сораулар белән яки киңәш белән килсәк тә ул безгә ярдәм итә. Галия апа безгә әдәбият, география һәм җыр дәресләрен укыта. Аның дәресләре кызыклы үтә. Миңа күбрәк әдәбият дәресе ошый. Анда төрле хикәяләр укыйбыз, язучылар тормышы белә танышабыз, шигырьләрне дә өйрәнәбез. Йомшак тавышы белән һәрбер авазны ачык әйтеп укыган вакытта без хикәянең эченә кереп китәбез.
Галия апа, сезне укытучылар көне белән тәбриклибез! Бик зур рәхмәт сезгә Галия апа!

*7 нче сыйныф укучылары исеменнән Гатина Фәйрүзә.*

…Кадрия апа – ул безнең беренче укытучыбыз. Без аңардан бик күп нәрсәләргә өйрәндек. Ул безне укый-яза белергә генә түгел, матур итеп җырларга да, рәсем ясарга да, чигәргә дә өйрәтте. Без барыбыз да аның дәресләрен бик ярата идек. Кадрия апабыз да һәммәбезне бертигез, үз балалары кебек ярата иде. Кайвакытта бик шаярып китеп, шуклыкларыбыздан башка фән укытучылары зарланса, ул безне алар алдында яклый да, аннары класска кергәч алай ярамаганлыгын бик әйбәтләп аңлата иде. Без дә һәрвакыт аны тыңларга тырыштык, аның йөзенә кызыллык китермәдек. Чөнки без дә аны ул безне яраткан кебек, чын күңелдән яраттык. Бездән аңа бер теләк: Кадрия апа, һәрвакытта шулай көләч йөзле, йомшак күңелле булып, укыткан һәм укытасы балаларның күңелләрендә матур хатирә булып сакланыгыз!

*Әбүнәгыймова Аделина 5 нче сыйныф.*

Хөрмәтле сыйныф җитәкчебез, Гүзәлия Идрисовна! Еллар буена җыелган тәҗрибәгез һәм түземлегегез белән безгә аң-белем бирүегез, үзегезнең бар көчегезне безне тәрбияләргә, чын кеше ясарга тырышуыгыз өчен дә сезгә зур рәхмәт.
...Сез безгә тормыш сукмагы буйлап атлап барырга көч бирдегез, ышаныч тудырдыгыз, күңелебезгә өмет чаткысы салдыгыз.

Сезнең өчен мәктәп изге йорт,
Үз итәсез һәрбер баласын.
Ачкыч табып сабый күңеленә
Белем орлыклары саласыз.
Күпме кыенлыклар кичергәнсез
Биргән чакта безгә тәрбия.
Хезмәтегез өчен һәр укучың
Хөрмәт белән бүген баш ия.

*11 нче сыйныф укучылары исеменнән Алия Закирова.*

Укытучылар көне уңаеннан безгә бик күп котлаулар килде. Газетабызның бу санына иң беренче килгән язмаларны урнаштырдык. Язмалары күренмәгәннәр борчылмасын, без аларны киләсе саннарда бирербез.

“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.
Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015